СОВЕТ ГОРОДА ЗАИНСКА
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Орджоникидзе, д. 49, г.Заинск, 423522

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗӘЙ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
Орджоникидзе ур.,49 йорт, Зәй шәһәре,423522

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

09.07.2021 г. Заинск № 60

**«Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре территориясендә файдаланылмый торган терекөмешле лампаларны җыюны оештыру турында» 2011 елның 25 октябрендәге 51 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре Советы карары үз көчен югалткан дип тану хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре территориясендә файдаланылмый торган терекөмешле лампаларны җыюны оештыру турында» 2011 елның 25 октябрендәге 51 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре Советы карары (2014 елның 23 гыйнварындагы 157 номерлы карар нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) үз көчен югалткан дип танырга.
2. Карарны Зәй муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Совет Рәисе** **Р.Г. Кәримов**